Сайфуллина Ф.С.

Казан шәһ.

# ИБРАҺИМ БИККОЛОВ ЗАМАНДАШЛАРЫ Ф.ӘМИРХАН ҺӘМ Г. ТУКАЙ ТУРЫНДА

**Аннотация.** В данной статье анализируются публицистические статьи известного в начале XX века педагога-просветителя, журналиста, общественного деятеля Ибрагима Биккулова, посвященные деятельности Ф. Амирхана и Г. Тукая. Являясь их современником, близким другом К. Бикколов высоко ценил творчество этих неординарных представителей татарской литературы начала XX века.

This article analyzes the journalistic articles known in the early twentieth century, the teacher-educator, journalist and public figure Ibrahim Bikkulov on activities F. Amirhan and G. Tukai. As their contemporaries, a close friend of I. Bikkolov highly valued work of these extraordinary representatives of the Tatar literature of the early twentieth century.

Бикколов Ибраһим Җамаледдин улы (1884-1938) – җәмәгать эшлеклесе, педагог, XX гасыр башында актив әдәби-публицистик эшчәнлек алып баручы журналист, тәрҗемәче. XIX йөзнең соңгы чирегендә татар дөнъясына мәгърифәтчелек идеаллары иңә, зыялыларның прогресс-тәрәккъыят хакында хыял-өметләр белән яши башлаган елларда Сембер губернасы Буа өязе, Суыксу волосте, Яңа Тинчәле авылында (хәзерге Татарстанның Буа районы) үз заманында танылган руханилар гаиләсендә дөньяга килә.

И. Бикколовның язмышы һәм эшчәнлеге хакында мәгълүматлар әлегә бик аз. Үз вакытында аның журналистика өлкәдәге эшчәнлегенә Г. Ибраһимов югары бәя бирә. [1, 29 апрель] 1930-1937 елларда шәхес культы корбаннары булган бик күпләр кебек, аның исеме дә озак заманнарга тарих битләреннән алып ташланды. XX гасыр ахырында гына Ибраһим һәм аның бертуган абыйсы – шагыйрь, мәгърифәтче язучы, гасыр башы мәктәп-мәдрәсәләре өчен дәреслекләр, уку китаплары төзүче Касыйм Бикколов турында кайбер мәгълүматлар дөнья күрде. Ибраһим Бикколовның эшчәнлеге, тормыш юлыннан аерым сәхифәләр Фатыйма Ибрагимованың XX гасыр ахырында «Казан утлары» журналы битләрендә басылган мәкаләсендә урын алды. [2, б. 188]

Яңарыш чоры татар тормышында, туган җирләре – Яңа Тинчәле авылының ике гасыр арасы хәятендә Бикколовлар нәселе кылган изге гамәлләр, калдырган мәдәни мирас киңкырлы. Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә белем алган этиләре Җамаледдиннең дә, Казан мәдрәсәләренең берсендә укыган олы улы – мәгърифәтче, дин белгече, шагыйрь, язучы Касыймның, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, гомерен укытучылык эшенә багышлаган, публицист булып танылган улы Ибраһимның да төрле төбәкләрдә таралып яшәгән татар кавемен белем-мәгърифәтле итү юлындагы хезмәтләре бәһәләп бетергесез. Бабалары – Габделлатыйф хәзрәт вә аның гаиләсе хакында Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабының «Шәхесләр һәм истәлекле вакыйгалар» бүлегендә [3, б. 283], Р. Фәхреддиннең атаклы «Асар» китабында [4, б. 136] шактый киң мәгълүматлар бирелгән.

Башлангыч белемне Буа мәдрәсәсендә алганнан соң, Ибраһим Бикколов Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Шунда ул татар әдәбиятының булачак классигы Фатих Әмирхан белән таныша, аларның дуслыгы Ф.Әмирханның вафатына кадәр дәвам итә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Ф. Әмирхан җитәкчелегендә оештырылган һәм 1905 елга кадәр эшләп килгән әдәбият түгәрәге әгъзалары арасында И. Бикколов исеме дә телгә алына. [5, б. 554]. Казанда татар шәкертләре тарафыннан оештырылган «Ислахчылар» хәрәкәтендә (1905-1906) актив катнашучылар буларак та Ф. Әмирхан, И. Бикколов исемнәре янәшә телгә алына. Б. Әхтәмов җитәкчелегендә социал-демократлар партиясенең татар группасы оешу турында мәгълүматларда да бу ике исемнең янәшә булуы, чыннан да, И. Бикколовның Ф. Әмирхан белән шактый тыгыз, дустанә мөнәсәбәтләрдә булуын дәлилли.

1906 елның 5 маенда Казанда приказчиклар клубында Н. Кямалның «Кызганыч бала» (Г. Камал тәрҗемәсе) һәм «Гыйшык бәласе» (Г. Кәрам тәрҗемәсе) пьесалары куелганнан соң И. Бикколовның «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» исемле мәкаләсе басылуы бу фикерне тагын да

көчәйтә. Мәкалә авторы спектакльләрдә Ф.Әмирханның баш рольләрне башкаруы хакында яза.

«Фатих Әмирхан турында истәлекләр» китабының төзүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән «Халык хәтерендә» дип аталган кереш сүзендә Ибраһим Бикколовның шәхесен ачуда гаять әһәмиятле булган түбәндәге сүзләр язылган: ««Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә бергә укыган дуслары Р. Алуши, В. Бәхтияров, И. Бикколовның тирән эчтәлекле истәлекләрендә әдипнең иҗтимагый эшчәнлеге алгы планга чыгарыла. ... Сүз уңаенда И. Бикколовның Ф. Әмирханны аеруча якын күрүен әйтергә кирәк. Әдип үлем түшәгендә ятканда ул гел аның янында була, вафатыннан соң җирләү эшендә башлап йөри, калган кулъязмаларын җыештырып, тәртипкә салып куя». [6, б. 13-19] Бу язма И. Бикколовның татар әдәбияты классигы Ф. Әмирхан тормышында гаять зур урын тотуын, ахыр көненә кадәр дусты һәм фикердәше булуын раслый. Шуның белән бергә, Ф. Әмирхан даирәсе белән дә аралашкан булуы хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Әлеге истәлекләр китабына И. Бикколовның «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» һәм «Мәрхүмнең авыруы» дип аталган ике мәкаләсе кертелгән. Мәкаләләрнең беренчесе бу китапка кыскартылып тәкъдим ителүенә карамастан, шактый зур һәм тирән эчтәлекле, яшьлек дусты – Ф. Әмирханның иҗтимагый эшчәнлегенә, аның дөньяга карашларының формалашуында, язучы булып җитлегүендә әһәмиятле урын тоткан мәдрәсә чорына, иҗатына шактый җитди бәя бирә: «Үзенең җитдилеге, үзен мөстәкыйль һәм хөр тотуы белән үзенә һәр дәмдә яшерен бер ихтирам тоттырган Фатихның шәкертләр арасында ихтирамы зур иде. Ул шул вакыттагы шәкерт хәрәкәтенең авторитетлы юлбашчысы булып китә алырлык бер хәлдә иде һәм иҗтимагый, сәяси тәрбиясе ягыннан да шуңар хәзерлекле иде. Шуңар күрә дә бик җиңеллек белән шәкерт хәрәкәтенең башында була алды. Ул шул томан хәлендә булган хәрәкәтләргә билгеле бер тон биреп торды, шәкертләрнең теләкләрен билгеле бер калыпка салды». [7, б. 14-20] Шунда ук И. Бикколов 1903-1904 елларда Ф. Әмирхан җитәкчелегендә әдәби түгәрәк төзелүе хакында яза һәм үзе дә шушы түгәрәк

әгъзасы буларак, шунда катнашучы дуслары Миргазиз Укмасый, Кашшаф Патый, Габдулла Сөләймани (казый), Гарифҗан Мостафа, Муллахмәт Бәдигый, Ибраһим Әмирхан, Вафа Бәхтияр исемнәрен телгә ала.

И. Бикколовның Ф. Әмирханга багышланган икенче мәкаләсе («Мәрхүмнең авыруы») язучының соңгы көннәре хакында бәян итә. «Мәрхүм, үләргә ун-унбиш минут калганчыга кадәр тәмам аңында булып, килгән кешеләрне танып һәм һәркайсы белән берәр сүз генә булса да сөйләшеп ятты. Соңгы өч-дүрт көн эчендә инде үзенең калуына өмиде бетә башлаган, үлемне җиңеллек белән каршы алырга хәзерләнгән иде... Мәрхүмнең күңел сизүе күп ялгышмады, сәгать ун тирәләрендә «Әйдә, киттек, күңелем рәхәтләнсен» сүзләрен әйткәч, озакламады – җан бирде». [8, б. 147-148] Язучы турында истәлекләрнең беренче басмасында мәкаләнең авторы И. Б. рәвешендә инициаллары белән генә тәкъдим ителсә, икенче басмада автор исеме тулысы белән «Ибраһим Бикколов» рәвешендә бирелә. «Хәбәрче» имзасы белән язылган мәкаләдә мәрхүмне озату мәрасимендә классик язучының тәрҗемәи хәле турында чыгыш ясаучы да дусты И. Бикколов булуы хакында мәгълүмат бирелә. [9, б. 151]

Журналистның 1915 елда «Кояш»та басылган «Татарча театр» [10, 11 февраль] дип аталган мәкаләсе Ф. Әмирханның яңа пьесасы – «Тигезсезләр»нең беренче тапкыр сәхнәдә куелуына мөнәсәбәтле языла. Мәкалә, бер яктан, әсәргә идея-эстетик кыйммәте ягыннан бәя бирергә омтылыш, икенче яктан бу фикернең сәхнәдә актерлар уены аша тормышка ашырылу дәрәҗәсен бәяләү ягыннан якын килгән булуы белән игъибарга лаеклы. Мәкалә авторы башта шушы вакыйганың халык тарафыннан ничек кабул ителүе – ягъни гасыр башы укучысы-тамашачысының яңа әсәргә, театр куелуга карата фикерен дә ачыклый. И. Бикколов бу мөһим вакыйганы журналистлык төгәллеге белән чагылдыра, замана атмосферасын тудыра, театр сәнгатенең үзенчәлекләрен исәпкә алып, анализ-бәяләмә бирә. Мәкаләнең төп өлешен, әсәрнең сәхнәдә куелышы һәм сәхнә шартларында идея-эстетик мәгънәсенең ачылу дәрәҗәсен бәяләү алып тора. Сәхнәдә яңа куелган әсәрнең геройлары белән таныштыру

барышында И. Бикколов аларга автор тарафыннан салынган фикер, персонажларның әсәрдә башкарган рольләре турында мәгълүмат бирү белән бергә, теге яки бу образга үзенең мөнәсәбәтен дә җиткереп бара. Мисалга, төп героиня Рокыяны «... гимназиядә укый, аны өй эчендә дә, өй тышында да һәммәсе яраталар. Ул үзе милләтче, чын-чын татар кызы» дип бәяләсә, студент Габдулла турында «татарларга бик түбән караучы, татардан бер эш тә чыкмаячак, татар милләте бетә торган халык, шуның өчен аңа хезмәт итеп, аны тәрәккъкый иттерергә тырышу да габис эш дип йөрүче татар Иванушкасы. Ул үзе татарча яза да белми, татарлар арасына да катнашмый, аларның мөхәррирләренә вә әдәбиятларына да бик түбән генә карыйдыр» дип бәя бирә. Шушы геройларга мөнәсәбәтле автор һәм Ф. Әмирханның, һәм үзенең милли идеаллары, татар халкының киләчәге хакында уйланулары белән бүлешә. Рокыя шикелле кызлары булган татар милләтенең киләчәге өметле дигән фикер әсәрнең үзәк фикере булуына басым ясый.

И. Бикколов актерларның уенына да шактый өзлекле, тәфсилле бәя бирә. Мәкалә авторы «Тигезсезләр» шикелле «хәрәкәт вә тирән рухка бай» пьесаларны уйнау бик җиңел эш булмавына басым ясый. «Сәяр» труппасының яңа гына сәхнәдә уйный башлаган яшь артистлары өчен бу спектакльдә уйнау җитди сынау булуын да искәртә. Аерым артистларның гримнары, мимикалары, киемнәре туры килмәү, кайберләренең артык тупас уйнавы «шундый нәфис вә матур пьесада ... сәхнәнең бөтен гармониясен бозып торды» дип бәяләнә.

Бу мәкаләсендә автор оста журналист буларак кына түгел, тирән белемле әдәбият тәнкыйтьчесе, әдәбият белгече буларак та ачыла.

Русиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татарларга милли белем тарату уе белән янып яшәгән бер төркем яшьләр арасында «Мөхәммәдия»не тәмамлаган И. Бикколов та була, ул ерак Себер шәһәрләренең берсе – Томскига мөгаллим булып китә (1906-1913). Ф. Ибраһимова язмасына караганда, Томскида нинди кыенлыклар белән балалар укытуы турында ул Ф. Әмирханга хатлар язып тора. И. Бикколовның журналистлык эшчәнлеге дә шушы елларда башланап китә. 1913-1916 елларда чыгып килгән вакытлы матбугат битләрендә И. Бикколов

имзасы белән басылган шактый мәкаләләрне очратырга мөмкин. «Шура», «Мәктәп», «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында аның үз чорының актуаль мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләре дөнья күрә; актив журналист буларак И. Бикколов «Әл-Ислах», «Сибирия», «Йолдыз», «Ил» кебек гәзитәләр белән дә хезмәттәшлек итә. «Әл-Ислах» гәзите һәм бу вакытлы матбугат басмасында язышкан татар прогрессив эшлеклеләре исемлегендә И. Бикколовны Михаэль Фридерих та телгә ала: «Почти все татарские литераторы и интеллектуалы того времени, проживавшие в Казани, сотрудничали в этой газете. Назовем для примера лишь некоторых – Фатих Амирхан, Галиасгар Камал, Галимджан Ибрагимов, Сагит Рамиев, Кабир Бакир, Миргазиз Укмаси, Ибрагим Биккулов, Султан Рахманкулый, Хусаин Ямашев». [11, б. 41] Ф. Әмирхан белән берлектә И. Бикколовның «Кояш» гәзитенең төп хезмәткәре булуы да мәгълүм. Аның исеме бу газетада язышучылар – Г. Тукай, Г. Ибраһимов, С. Сүнчәләй, С. Рәмиевлар белән беррәттән телгә алына.

Шушы заман татар әдәбиятының йөзен билгеләүчеләрдән Г. Тукайга мөнәсәбәтле мәкаләләре шундыйлардан. «Тукай «Әлислах» идарәсендә» [12, 2 апрель] дигән истәлегендә аның белән ничек танышуы хакында яза: «Тукай белән «Әл-ислах» идарәсендә таныштым һәм аның белән бик тиз дуслаштык, бергә эшли, бергә яза торган идек».

И. Бикколовның Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан караганда шул заманда Томск каласында нәшер ителә башлаган «Сибирия» гәзитендә дөнья күргән «Габдулла әфәнде Тукаев» [13, 7 апрель] мәкаләсе игътибарга лаеклы. Тукай вафаты хакындагы авыр хәбәрне И. Бикколов Томскта ишетә. Берничә ел Себер якларында мөгаллимлек иткән татар интеллигенты, журналист, әлбәттә, Тукай үлеме белән бергә татар әдәбиятының зур югалтуы хакында язмый кала алмый. Мәкалә, беренче чиратта, дустанә интонация, рухи якынлык белән язылган булу ягыннан игътибарны җәлеп итә. (Гәзитнең бу санында мәкалә белән бергә шагыйрьнең фоторәсеме дә бирелә) Мәкалә авторының Г. Тукайга мөнәсәбәте, аның вафатын иң якын кешесен

югалткан кебек кабул итүе, шагыйрьнең үз иҗаты кебек бер үк вакытта гади һәм тирән әрнү белән язылган булуы беренче юлларыннан ук аңлашыла. Мәкалә бөтен татар халкы исеменнән языла: «Башыбызга бәхетсезлек килә генә тора, бер кайгыны онытырга өлгермибез, аңардан куркынычрак вә аңардан да күңелсезрәк булганнары килеп торадыр. Тәкъдир бер кешегә яки бер халыкка каһәрен салса, сала да сала гына, аны изгәннән изә генә бара.

Менә иң талантлы шагыйребезне, иң беренче әдибебезне дә югалттык. Габдулла Тукаев – бу зат бит һәрбер татарның иң сөйгәне вә иң якын күргәне бер зат иде. ... Менә явыз тәкъдир шушы бөтен милләтнең чын күңеле илә сөеп тоткан иң кадерле бер кешесен күзен дә йоммыйча алды да китте. Яшь кенә сабый хәлендә булган татар әдәбияты вә татар теленең бик яшьли үксез калам бит, диеп елавына да илтифат итмәде, миллионнарча рухларның гали татар поэзиясе илә гыйзаланудан[1] мәхрүм калуларына да игътибар итмәде. Аларны акыртып-бакыртып үксез итеп калдырды».

И. Бикколов бу мәкаләсендә замандашы, иҗатташы, күңеленә, рухына якын булган шагыйрь иҗатының бөтен татар дөньясы өчен кыйммәтле, якын булуын, аның мәңге укылып туймаслык “Печән базары”, “Шүрәле”, “Бәйрәм бүген” кебек әсәрләре халык хәтерендә саклануын яза. Мәкаләдә авторның Г. Тукай шәхесенә мөнәсәбәте, аның татар әдәбиятында toткан урынына югары бәясе чагылыш таба. «Габдулла әфәнденең болай безне иртә ташлавы, аңарда киләчәктә бик зур өметләрнең булуы бу матәмне безгә ике өлеш авыр итәдер. Ул әле бик яшь, аңарда киләчәктә бик зур өметләр бар иде. Хосусан, Габдулла әфәнденең рухындагы еш алышынулар һәм бу алышынуларның көннән-көн Габдулла әфәндедә шигърият куәтенең арта баруына хезмәт итүе бу өметләрне куәтлидер иде». Шул заман вакытлы матбугатында лейтмотив буларак яңгыраган «бик яшьли дөньядан китсә дә, шагыйрьнең исеме татар халкының күңелендә мәңге сакланачак» фикер И. Бикколов мәкаләсенең дә төп аһәне тәшкил итә.

[1] Гыйзалану – ризыклану, туклану.

Мәкаләсен йомгаклап, автор түбәндәгеләрне яза: «Хәзер безгә Габдулла әфәнденең Толстой хакында әйтдеке «Тәсбих өзелде» сүзләрен тәкърарлап, Гаяз, Әмирхан, Сәгыйтьләр вә Гафурилар кебек мөхтәрәм затларыбыздан төзелгән тәсбих өзелде, шушы тәсбихнең иң кыйммәтле бер төймәсе дә җиргә төшеп югалды, мәңге табылмаска югалды, диеп тәкъдирнең бу каты золымына баш кына ияргә калды».

Бу мәкалә И. Бикколовны заман сулышын, әдәби хәрәкәтне нечкә тойган, талымлы, белемле журналист һәм тәнкыйтьче буларак таныта. Матбугат битләрендә И. Бикколовның атаклы шәхесләребез Исмәгыйль Гаспралы, Шиһабеддин Мәрҗаниләр эшчәнлеге, гомумән, гасыр башы татар әдәби хәрәкәте, вакытлы матбугат торышы, илдәге сәяси һәм икътисадый тормыш хакында саллы, гомумиләштерү характерындагы мәкаләләре дөнья күрә. «Петербургта мөселман съезды» [14, б. 250-252], «Гомумауропа сугыш алдында» [15, б. 267-268], «Бөтен дөнья сугыш алдында» [16, б. 285-286] мәкаләләрендә авторның шушы вакыйгага мөнәсәбәте чагылыш таба. И.Бикколовның аналитик характердагы, вакытлы матбугатның ел нәтиҗәләре буларак тәкъдим ителгән «Үткән 1914 ел» [17, б. 19-24.], «Үткән 1915 ел» [18, б. 51-54] мәкаләләрен күрсәтергә мөмкин.

Шул рәвешле, алдынгы карашлы рухани гаиләсеннән чыгып, ике гасыр арасы кебек катлаулы чорда үз юлын укытучы эшеннән тыш, журналист, публицист буларак билгеләгән, шушы юнәлештә шактый күләмле хезмәтләр калдырган Ибраһим Бикколовның XX гасыр башы татар милли хәрәкәтендә, иҗтимагый тормышында, вакытлы матбугат үсешендә тоткан урыны гаять зур, әһәмиятле. Бу юнәлештәге башкарган эшебез төгәлләнгән булуга дәгъва итми. Исеме үз заманы татар җәмәгатьчелегенә шактый киң мәгълүм булган укытучы, шул заман әдәби барышының асылын тәшкил иткән әдипләр белән бергә кулына каләм алган, соңрак шәхес культы корбаны булган И. Бикколовның әлеге чор вакытлы матбугаты битләрендә дөнья күргән публицистик мирасын барлау, аны замана әдәби торышы кысаларында тәфсилләп өйрәнү, һичшиксез, дәвам иттерелергә тиеш.

## Әдәбият:


1. Ибраһимов Г. Яңа имзалар вә яшь куәтләр // Йолдыз. – 1915. – 29 апр.
2. Ибраһимова Ф. Тарих сәхифәләрендә – татар шәхесләре. Ибраһим Бикколов // Казан утлары. – 1994. – №6. – Б. 188.
3. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. - Б. 283.
4. Фәхреддин Р. Асар. – Казан: «Рухият» нәшрияте, 2010. – Б. 136.
5. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда, 3 Т. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – Б. 554.
6. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / төз. Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан (тулыланд. икенче басма). - Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – Б. 13-19.
7. Бикколов И. Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – Б. 14-20.
8. Бикколов И. Мәрхүмнең авыруы // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – Б. 147-148.
9. Хәбәрче. Фатих Әмирханны соңгы юлга озату // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – Б. 151
10. Татарча театр // Кояш. – 1915. – № 627. – 11 февраль.
11. Фридерих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. – Казань: Татар.книжн.изд., 2011. – Б. 41.
12. Бикколов И. Тукай «Әл-Ислах» идарәсендә // Ак юл. – 1914. – 2 апрель.
13. Бикколов И. Габдулла әфәнде Тукаев // Сибирия. – 1913. – 7 апрель (№ 96).
14. Петербургта мөселман съезды // Аң. – 1914. – № 13. – Б. 250-252.
15. Гомумауропа сугыш алдында // Аң. – 1914. – № 14. – Б. 267-268.
16. Бөтен дөнья сугыш алдында // Аң. – 1914. – № 15. – Б. 285-286.
17. Үткән 1914 ел // Аң. – 1915. – № 1. – Б. 19-24.
18. Үткән 1915 ел // Аң. – 1916. – № 3. – Б. 51-54.